| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Урман Асты Шонталасы ав.

28.06.2021 № 8

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау Тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау тәртибенең бердәм тәртибен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән вакытта Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Ә.Җиһаншин**

Алексеевск муниципаль районының
Урман Асты Шонталасы авыл
җирлеге башкарма комитетының
2021 елның
28 июнендәге 8номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән
гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнгән һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына килгән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшенең сыйфатын яхшырту, гражданнарның җәмәгать фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын арттыру максатларында уздырыла.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда кергән барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язма рәвештә дә, электрон документ рәвешендә Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган электрон документ рәвешендә, шулай ук гражданнарны вәкаләтле затлар тарафыннан шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

5. Киләсе хисап чорының айның 10 числосына кадәр гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзелә.

6. Аналитик белешмәдә гражданнарны шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда алдагы елның шушы чорына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Башкарма комитет сәркатибе ел саен аналитик белешмәне авыл җирлегенең рәсми сайтында «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.